# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы**
**Тауасты Байлар авыл җирлеге Тауасты Байлар**
**торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында**

**27 ноябрь 2023ел** **№ 6**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 27.11.2023 гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча халык җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде: «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Тауасты Байлар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә ризамы,1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Тауасты Байлар торак пунктында Яшел урам буйлап вак таш сатып алу һәм салу (килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтү өчен түләү);
- Тауасты Байлар торак пунктында кышкы чорда юлларны грейдирлау (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 298 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны – 167 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 167 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Тауасты Байлар торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. Сорау буенча карар кабул ителде дип танырга: «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Тауасты Байлар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә ризамы,1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек

Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Тауасты Байлар торак пунктында Яшел урам буйлап вак таш сатып алу һәм салу (килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтү өчен түләү);
- Тауасты Байлар торак пунктында кышкы чорда юлларны грейдирлау (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Тауасты Байлар авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:/ / pravo. tatarstan. ru) кабул ителгән көннән 10 көн эчендә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Тауасты Байлар авыл җирлеге башлыгы:______________________З.С.Гәрәева
(имза)